ГЛАВА
ВВЕДЕНСКО-СЛОБОДСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВВЕДЕНСКИЙ БИСТӘСЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

07.11.2024 с. Введенская Слобода №5

«Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге
Елизаветино авылында гражданнардан үзара салым акчаларын кертү һәм
алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре бюджетларына 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән (29.11.2023 ел № 1532 редакциясендә)

КАРАР БИРӘМ:

1. 2024 елның 23 ноябренә Югары Ослан муниципаль районының Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Елизаветино авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:
«Югары Ослан муниципаль районы Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Елизаветино авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2025 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертү һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә сез риза булырсызмы:
- Елизаветино авылының торак пункты чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту

«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Йорт яны территориясендә гражданнар җыенын түбәндәге адрес буенча уздырырга: Елизаветино авылы, Кояшлы урамы, 19 йорт 12:00 сәгатьтә.

4. Введенский Бистәсе авыл җирлегенең Башкарма комитетын гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Введенский Бистәсе авыл җирлеге башлыгы Д.В. Морозов